КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 гыйнвар г.Казань № 30

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе бүлекләрендә һәм филиалларында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 апрель, 293 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 2 март, 128 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 987 нче; 2017 ел, 8 сентябрь, 642 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 820 нче; 2018 ел, 24 июль, 585 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 һәм 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Учреждение хезмәткәрләренең иң чик штат санын вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 11 908 841 сум күләмендәге айлык фонды белән 885 берәмлек итеп билгеләргә.

6. Учреждениедә хезмәт өчен түләү системасын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенә караган аерым

оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карары нигезендә билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә, «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенең оештыру структурасын билгеләнгән тәртиптә билгеләгәннән соң ике ай эчендә бу карар нигезләмәләренә туры китерү өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 27 сентябрь, 860 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин